Рәхмәтуллина, Р. «Шигъри мәйдан»га җыелдык : [Чаллы Үзәк китапханәсенең Әдәбият музеенда «Шигъри Мәйдан» дип исемләнгән әдәби кичә узды] / Р. Рәхмәтуллина // Мәйдан. – 2025. – № 12 (289). – Б. 151.

# «Шигъри мәйдан»га җыелдык


Чаллы Үзәк китапханәсенең Әдәбият музеенда «Шигъри Мәйдан» дип исемләнгән әдәби кичә булып узды. Ул «Мәйдан» журналы, Чаллы Үзәк китапханәсе һәм Татарстан Язучылар берлеге Чаллы бүлегенең уртак проекты итеп оештырылды.


Әдәбият музее хезмәткәре Роза Хәмидуллина каләм ияләрен музейдагы яңа җиһазлар – интерактив терминаллар белән таныштырды.

– Сезнең турыда мәгълүматлар моңа кадәр кәгазь папкаларда саклана иде. Без Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге ярдәме белән грант отып, музейны заманча җиһазлауга ирештек. Терминалларны тулыландыру өчен без үзегездән дә мәгълүматлар көтәбез, – дип мөрәҗәгать итте ул каләм ияләренә.

Кичәдә Берлекнең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин да чыгыш ясады.

– Бу безнең хыял иде, – диде ул.





*Сәхифә өчен фотолар Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлегеннән алынды.*

«Шигъри мәйдан» бу юлы Әниләр көненә багышланган иде. Чаллы, Түбән Кама шәһәрләреннән, Кама Аланыннан килгән әдәби берләшмә әгъзаларының, Сирень Якупова, Рәкит Аллабирде, Лилия Гыйбадуллина, Рәзинә Мөхияр һәм башка әдипләрнең шигырьләре яңгырады. Кичә матур җырлар белән үрелеп барды.

Эшмәкәр Алсу Рәхмәтуллина язучыларга китапларын электрон сатуда ярдәм итү тәкъдиме белән чыкты.

Форсаттан файдаланып, без – «Мәйдан» журналы редакциясе – «Авыл шагыйре» бәйгесенең «Тәүге хикәя» номинациясендә 3 нче урын яулаган Шәҗәрә Нургатинаны диплом белән бүләкләдек. Ә «Мәйдан» журналының барлык әдәби проектларын тормышка ашыруда ярдәм күрсәткән язучы Сирень Якуповага «Рәхмәт хаты» тапшырылды.

**Ризидә РӘХМӘТУЛЛИНА.**